**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кырынды торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2021 елның 3 декабре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кырынды торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча 2021 елның 3 декабрендә 15 сәгать 00 минутта, 17 сәгать 00 минутта, 19 сәгать 00 минутта уздырылган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» Кырынды торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Кырынды авылында җирләрне ызанлау, су җыю скважиналары өчен техник документация рәсмиләштерү;

2. Түбәндәге адреслар буенча урнашкан су белән тәэмин итү чыганакларын һәм эчәргә яраклы билгеләнештәге су үткәргечләрне санитар саклау зоналарын (ЗСО) оештыру өчен төзелеш материаллары (торбалар, профильле торбалар, рабица челтәре) сатып алу:

- Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Кырынды авылы, Киров ур., 57 й., 1 нче су җыюскважинасы;

- Татарстан Республикасы, Әгерҗемуниципаль районы Кырынды авылы, Совет ур., 3 нче су җыю скважинасы.

3. ЭЦВ6-6,5-90 тирәнлек насослары алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 370 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны – 201 кеше, бу 54 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 201 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кырынды торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» Кырынды торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, иреклəреннəн мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Кырынды авылында җирләрне ызанлау, су җыю скважиналары өчен техник документация рәсмиләштерү;

2. Түбәндәге адреслар буенча урнашкан су белән тәэмин итү чыганакларын һәм эчәргә яраклы билгеләнештәге су үткәргечләрне санитар саклау зоналарын (ЗСО) оештыру өчен төзелеш материаллары (торбалар, профильле торбалар, рабица челтәре) сатып алу:

- Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы,  Кырынды авылы, Киров ур., 57 й., 1 нче су җыю скважинасы;

- Татарстан Республикасы, Әгерҗемуниципаль районы Кырынды авылы, Совет ур., 3 нче су җыю скважинасы.

3. ЭЦВ6-6,5-90 тирәнлек насослары алу һәм урнаштыру.

4. "Беларус 82.1" тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

4. Әлеге карарны Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырыга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы А. А. НАФИКОВ